КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 23 май г.Казань № 431

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Чирмешән авылында урнашкан «Нурлат аграр техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе филиалын бетерү һәм аның базасында «Чирмешән аграр техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен төзү турында

Һөнәри белем бирү белән идарә итү системасын камилләштерү һәм уку-укыту-тәрбия бирү барышын оештыруны тикшерүдә тотуны көчәйтү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы, Чирмешән авылы, Полевая урамы, 1 нче йорт адресы буенча урнашкан «Нурлат аграр техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе филиалын (алга таба – Чирмешән филиалы) бетерү һәм аның базасында 2019 елның 1 сентябреннән Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләрен үтәү өчен һәм урта һөнәри белем бирү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү максатларында мөстәкыйль юридик зат – «Чирмешән аграр техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен төзү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына:

«Чирмешән аграр техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен (алга таба – Чирмешән аграр техникумы) гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга;

өч эш көне эчендә Чирмешән филиалын бетерү турында кабул ителгән карар хакында теркәүче органга хәбәр итәргә;

14 көн эчендә:

Чирмешән филиалын бетерү комиссиясе составын расларга;

Чирмешән филиалын бетерү тәртибен һәм вакытларын Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә билгеләргә;

30 көн эчендә:

«Нурлат аграр техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе (алга таба – Нурлат аграр техникумы) уставына үзгәрешләр кертергә;

Чирмешән аграр техникумы уставын эшләргә һәм расларга;

Нурлат аграр техникумында һәм Чирмешән аграр техникумында укучыларны әзерләү алып барылачак белгечлекләр исемлеген билгеләргә;

Чирмешән аграр техникумы өчен гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсен эшләргә;

Чирмешән филиалында укучыларны Чирмешән аграр техникумына, Чирмешән филиалында гамәлдә булган уку-укыту шартларын һәм программаларын саклап, ата-аналар (законлы вәкиләр) ризалыгы белән күчерергә;

Чирмешән филиалын бетерү буенча законнарда күздә тотылган башка чараларны гамәлгә ашырырга, шулай ук бетерелү аркасында эштән азат ителә торган хезмәткәрләргә Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Чирмешән аграр техникумына оператив идарә хокукында тапшырылырга тиешле мөлкәт исемлеген, шул исәптән күчемсез мөлкәт объектларына техник документацияне Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына кертергә.

3. Чирмешән аграр техникумының дәүләт йөкләмәсен үтәвен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карарында билгеләнгән тәртиптә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында әлеге максатларга каралган акча чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына:

бу карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән мөлкәт исемлеге Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан бирелгәннән соң 30 көн эчендә тиешле мөлкәтне оператив идарә хокукында Чирмешән аграр техникумына беркетергә;

120 көн эчендә Чирмешән аграр техникумына беркетелә торган күчемсез мөлкәт объекты урнашкан җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында бирергә.

5. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, бу карарның 2 – 4 нче пунктлары үтәлгәннән соң 30 көн эчендә

Татарстан Республикасы һөнәри белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын билгели торган норматив хокукый актларга аларны бу карарның 1 нче пунктына туры китерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр әзерләргә һәм аларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин